**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәсгут авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәсгут авылы № 140-81 «15» октябрендәге 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 88 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләрне кертү хакында 05.10.2018 №102, 29.11.2018 №110, 23.09.2020№9-2, 20.10.2022 №71-36, 22.02.2023 №81-44, 07.06.2024 №127-73) карарлар редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турындагы 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы” карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә

Мәсгут авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 88 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы

Мәсгут авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә (05.10.2018 №102, 29.11.2018 №110, 23.09.2020№9-2, 20.10.2022 №71-36, 22.02.2023 №81-44, 07.06.2024 №127-73)карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.5 пунктында «13323,00» санын «13990,00» санына алмаштырырга.

1.2. Азнакай муниципаль районының Мәсгут авылы җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны, әлеге карарга кушымта нигезендә, яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А.Вильданов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советы карарына кушымта
«15» октябрь 2024 № 140-81

### Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башлыгы, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларның айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Авыл җирлекләрендә | |
|---|---|---|
| | 11 төркем | 12 төркем |
| 1 | 2 | 3 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 20 991 | 19 173 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 15 085 | 13 991 |
| Депутатлар | 13 990 | 13 990 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 13 990 | 13 990 |